**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 6 август № 533

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче; 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы; 2010 ел, 29 март, 199 нчы; 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2011 ел, 13 август, 676 нчы; 2012 ел, 3 февраль, 81 нче; 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче; 2013 ел, 14 март, 159 нчы; 2013 ел, 8 апрель, 238 нче; 2013 ел, 4 июнь, 384 нче; 2013 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 818 нче; 2014 ел, 13 август, 590 нчы; 2014 ел, 11 ноябрь, 854 нче; 2015 ел, 20 март, 174 нче; 2015 ел, 04 июнь, 407 нче; 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.1.82.4, 4.1.82.5 пунктчалар өстәргә:

«4.1.82.4. Террорчылыкка каршы тору буенча чараларны тормышка ашырганда Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары белән багланышларны көчәйтү максатларында укулар үткәрүдә катнаша.

4.1.82.5. Министрлыкның террорчылык чагылышы нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү өчен билгеләнгән көчләрен һәм чараларын нәтиҗәле куллануга даими әзерлек хәлендә тота.»;

түбәндәге эчтәлекле 6.1.1 пункт өстәргә:

«6.1.1. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

6.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле алтынчы – тугызынчы абзацлар өстәргә:

«министр урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре исемлеген боерыгы белән раслый;

Министрлыкка беркетелгән процессларны (ярдәмче процессларны) үтәү стандартларын боерыгы белән раслый һәм аларның үтәлешен тәэмин итә;

төп нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү нәтиҗәләре нигезендә министр урынбасарлары, Министрлыкның структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү турында Министрлык буенча нигезләмәне, шулай ук эшчәнлек нәтиҗәлелегенең ирешелгән төп күрсәткечләренә бәйле стимуллаштыручы түләүләр күләмен исәпләү тәртибен билгеләү турында нигезләмәне боерыгы белән раслый;

Министрлык өчен билгеләнгән төп нәтиҗәлелек күрсәткечләре һәм хезмәт законнары нигезендә үз карамагындагы учреждениеләр җитәкчеләре белән контрактлар (хезмәт шартнамәләренә өстәмә килешүләр) төзи.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков